С. МАРШАК

ТӨРЛЕ БУЯУЛЫ КИТАП



В. ЛЕБЕДЕВ РӘСЕМНӘРЕ

ТАТГОСИЗДАТ
1951

С. МАРШАК

ТӨРЛЕ БУЯУЛЫ КИТАП



В. ЛЕБЕДЕВ рәсемнәре

ТАТГОСИЗДАТ
ЯШЬЛӘР-БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ СЕКТОРЫ
КАЗАН 1951

Китапның бу бите—яшел, чәчәкле-гөлле.
Шулай булгач, анда һаман матур җәй көне.
Сыя алсам китаптагы шушы урынга,
Ятар идем мин ял итеп яшел болында.

Үрмәли алтын бөҗәкләр үлән эчендә,
Куна энәкарагы ак чәчәккә килеп.
Ул тирбәлеп утыра әнә чәчәк өстендә,
Үзе—зәңгәргә буялган самолёт кебек.

Менә нәни коңгыз кызыл киемен кигән,
Ул, аркасын ачып, җәя кинәт канатын,
Очып китә тыныч кына барган җиреннән,
Башкарасы бик күп эше бар икән аның.


Әнә апалы-сеңелле кызлардай тагын,
Бер төстәге күбәләкләр үләнгә куна.
Я бер ябып чуар китап кебек канатын,
Я бер ачып—оча алар яңа урынга.



Ә бу биттә диңгез җәелеп ята:
Җир бер дә юк анда — гел сулар,
Зур кораблар әнә йөзеп бара,
Юлларында уйный дулкыннар.

Дельфиннар да анда күренеп китә,
Күчеп йөри диңгез йолдызы.
Үсемлекләр чайкалалар төптә,
Җил юк анда — чайкый су үзе.

Күр, бу битнең аскы өлешендә
Диңгез төбе кебек караңгы.
Фонарьлар юк, ләкин су төбендә
Балыклар бар — якты фонарьлы.







Сез яратасыз, балалар,
Уйнарга комда.
Соскыч, көрәк, нәни чиләк
Аласыз кулга.

Салкын, сары комны учлап,
Кулыңа алсаң,
Ком, алтын тасмага охшап,
Түгелә аннан.

Тигез итеп ком сибелә
Бакчада юлга.
Ләкин начар — әгәр җирдә
Ком бик күп булса.



Менә сары биткә кара —
Чүл ята көеп.
Комнар күчә, комнар ага,
Дулкыннар кебек.

Әнә сахралар поезды —
Дөяләр бара.
Билгесез, аларның юлы
Кайларга таба?..

Кыңгыраулар, моң таратып,
Чыңлый далада.
Ә агачлар, комга ятып,
Үсәләр анда.

Үсә нык һәм чыдам агач —
Саксаул монда.
Яфраксыз ул, шыр ялангач,
Иелгән комга.

Үрмәләп, грузовиксыман,
Ташбака чыга.
Башын тыга куркуыннан
Таш якасына.

Ком болытлары гел ага —
Куа чүл җиле.
Ком оча, һөҗүмгә бара
Гаскәр шикелле!

Бу — ак кар бите була.
Шуннан бер төлке уза,
Койрыгын болгый-болгый.

Аяз көнне бу биткә
Кошлар эз салып киткән,
Сикерешеп уйный-уйный.

Чаналар киткән узып,
Көмештәй эзләр сызып,
Ялтырый алар нурда.

Әнә иртәнге карда
Аяк эзләре калган,
Икәү булганнар монда.

Ике эз: алда бабай,
Ә арттан барган малай,
Бер эз урманда беткән.

Ә бер эз илтә ярга.
Кемдер баш түбән анда
Карга мәтәлеп киткән.





Җиденче ноябрь бүген,
Календарьда кызыл көн.
Син тәрәзәдән кара:
Урам кып-кызыл анда.

Ялкынлы кызыл флаглар
Бар җирдә җилфердиләр.
Уйнап килә музыкантлар —
Трамвайлар йөрмиләр.

Туган илдә яше-карты
Шатланып бәйрәм итә,
Кара минем кызыл шарны,
Һавага очып китә!



Менә тагын бер бит, бу—төн бите,
Башкалада инде караңгы.
Трамвайлар ял итәргә китте,
Автобуслар күптән таралды.

Йоклар өчен халык ашыга өйгә,
Күренмиләр тышта балалар.
Йокламыйлар тик сәгатьләр генә,
Йокламыйлар завод, вокзаллар.

Москва йортларыннан төшкән нурлар
Аллеялар буйлап тарала.
Тәрәзәдән балкып торган утлар
Берәм-берәм сүнә калада.

Кара-каршы очрап һәр чатлыкта,
Күпер аша уза фонарьлар,
Ә йолдызлар биек ераклыкта—
Күктә җем-җем итеп яналар.

Борынгы таш стенадан калкып,
Бөтен Совет иле күгендә,
Яна, кораб утларыдай балкып,
Кремль рубиннары бүген дә.

3 сум 65 тиен.

С. Маршак.

РАЗНОЦВЕТНАЯ КНИГА

(на татарском языке)

Тәрҗемәчесе *Н. Арсланов*

Редакторы *Ш. Мөдәррис*

Художество редакторы *Ш. Мөхәммәтҗанов*

Техник редакторы *Х. Рәкипов*

Корректоры *Х. Нәбиуллин*

Производствога бирелде 17/V-51 ел. Басарга кул куелды 22/VI-51 ел. ПФ 13094. Учетн. изд. 3,02 таб. Кәгазь форматы 60x92 1/8. Кәгазь таб. 1. Басма табак 2. Тираж 8065 экз. Заказ 152/710. Бәясе 3 сум 65 тиен.

Издательстволар һәм Полиграфия управлениесе каршындагы Офсет-фото-цинкографиясендә басылды. Казан, Бауман урамы 19, 1951 ел.